УДК 792.8

*Л.Р. Петрова*

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ ТЕАТРЫ: ҮСЕШЕНЕҢ АЛШАРТЛАРЫ, ЭШЧӘНЛЕК, НӘТИҖӘЛӘР

Статья освещает деятельность Татарского государственного театра оперы и балета в годы Великой Отечественной войны (1941–1945). На данном этапе театр столкнулся с трудностями (сокращение штата, отсутствие собственного помещения), но продолжил плодотворную работу: осуществлялась активная концертная деятельность (в том числе выступление в госпиталях), появлялись новые спектакли. Состоялись премьеры опер «Башмагым» («Башмачки»), «Акчарлаклар» («Чайки») Дж. Файзи. «Царская невеста» Н. Римского-Корсакова, «Кармен» Ж. Бизе, «Ильдар», Н. Жиганова, «Русалка» А. Даргомыжского, «Паяцы» Р. Леонкавалло, «Фарида» М. Юдина, одноактный балет «Вальпургиева ночь» Ш. Гуно, возобновили оперу «Алтынчеч» Н. Жиганова. Период также связан с развитием балетного искусства, оттачивалась форма национального балетного спектакля. В 1944 году была показана танцевальная сюита «Молодежь на отдыхе», музыка А. Ключарева, балетмейстер Г. Тагиров. В 1945 году состоялась премьера первого татарского балета «Шурале» Ф. Яруллина, балетмейстеры Л. Жуков, Г. Тагиров.

**Ключевые слова:** Татарский государственный театр оперы и балета, театр в военный период, национальный репертуар, Г. Тагиров, концертные бригады

The article covers the activities of the Tatar State Opera and Ballet Theatre during the Great Patriotic War (1941–1945). At this stage, the theatre faced difficulties (staff reduction, lack of its own premises), but continued its fruitful work: active concert activities (including performances in hospitals), and the creation of new productions. The premieres of the operas “Bashmagym” and “Akcharlaklar” (“Seagulls”) by J. Faizi took place. The company has performed Rimsky-Korsakov’s “The Tsar’s Bride”, Bizet’s “Carmen”, Zhiganov’s “Ildar”, Dargomyzhsky’s “Rusalka”, Leoncavallo’s “Pagliacci”, Yudin’s “Farida”, and Gounod’s one-act ballet “Walpurgisnacht”. They have also revived Zhiganov’s opera “Altinchay”. The period was also associated with the development of ballet art, and the form of the national ballet performance was refined. In 1944, the dance suite “Youth on Vacation” was performed, with music by A. Klyucharev and choreography by G. Tagirov. In 1945, the premiere of the first Tatar ballet “Shurale” by F. Yarullin took place. The ballet was choreographed by L. Zhukov and G. Tagirov.

**Keywords:** Tatar State Opera and Ballet Theatre, theatre during the war period, national repertoire, G. Tagirov, concert brigades

Бөек Ватан сугышы елларында сәнгать совет халкының какшамас рухын ныгыта, җиңүгә ышанычын арттыра. Фаҗигалы вакыйгаларга җавап буларак кино, театр, әдәбият, музыка, сынлы сәнгать әсәрләре иҗат ителә, аларда халкыбызның батырлыгы чагылыш таба, аның намусы, югары әхлакый сыйфатлары ассызыклана. Сәнгать

эшлеклеләре сугыш кырында да, тылда да уртак җиңүгә үз өлешләрен кертәләр. Сугыш елларындагы актив эшчәнлек нәтиҗәсендә яңа жанрлар, яңа формалар барлыкка килә.

ТАССРда бу чорда шулай ук сәнгатьнең төрле төрләре (театр, музыка, сынлы сәнгать) актив үсә. Моңа күп очракта сугышка кадәр барган процесслар да йогынты ясый. Әлеге мәкаләдә Татар дәүләт опера һәм балет театрының берничә юнәлештә алып барылган эшчәнлеге игътибар үзәгенә куела. Бу исә театрның алга таба үсешенә дә уңай тәэсир итә.

Театр 1939 елда ачыла. Труппаны Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен тәмамлаучылар нигезли. Репертуар формалаштыру эше оештырыла: бөтен дөнья театрлары репертуарындагы спектакльләр куела башлый, милли спектакль тудыруның әһәмияте зур була. Татар дәүләт опера һәм балет театры дирекциясе боерыгында болай диелә: «Считать за профиль театра, как стилевое творческое направление театра, что театр является национальным татарским государственным оперным театром с подлинно национальным оперным репертуаром в основном, с постановкой некоторых опер и на русском языке» [10: 39].

1941 елның августында Мәскәүдә узачак татар сәнгате декадасына әзерлек театрның динамик үсешенә зур этәргеч була. Казанга Мәскәү, Ленинград һ. б. шәһәрләрдән режиссёрлар, дирижёрлар, концертмейстерлар һәм башкаручылар эшкә чакырыла. Әлеге вакыйгалар республикада балет сәнгате үсешенә аеруча зур йогынты ясый. Белгечләр арасында – танылган балетмейстерлар П. Гусев, Л. Якобсон, профессиональ биючеләр Н. Балтачеева һәм Г. Кумысников, балет труппасы оешкан чорда алар театрның профессиональ үсешен тәэмин итә. 1939 елда балет труппасы опера театры каршында оештырылган зур булмаган хореография коллективыннан гыйбарәт була, ул 24 артисттан торып, алар арасына хореография белеме булмаган башкаручылар да керә. Составы зур булмаса да, труппа эшли башлаган елларны уңышлы һәм бай дип характерларга мөмкин. Труппаның җитәкчесе итеп 1938 елда Мәскәүдә укып кайткан Г. Таһиров билгеләнә. Хореограф Н. Җиһановның «Качкын» (1939), «Алтынчәч» (1941) операларына да бию күренешләре кертә, шулай ук бию Ш. Гуноның «Фауст», Дж. Вердиның «Риголетто» операларын да бизи. Балет спектакльләре әзерләнә – 1939 елның сентябрендә Зур рус драма театры сәхнәсендә П. Гертельнең «Тщетная предосторожность» балетының премьерасы була. Татар труппасы үз үсешенең барлык этапларында да классик мираска тугры кала. Сугыштан соңгы чор авырлыкларына карамастан, тамашачы күп актлы, катлаулы классик балетларның премьераларын күрә: А. Аданның «Жизель» (1945), П. Чайковскийның «Аккош күле» (1947), Л. Делибның «Коппелия»сен (1948). Сугыш чорында Ш. Гуноның «Вальпургиева ночь» акты куела (балетмейстеры Г. Таһиров).

Балет труппасы үсешенең әлеге этабына Гай Хаҗи улы Таһировның керткән өлешен һәм аның әһәмиятен ассызыклау аеруча зарур. Актёр, биюче, балетмейстер Таһиров балет театрының гына түгел, драма театрының да табигатен яхшы белә. Республиканың хореография сәнгате, хореография белеме үсешенә зур йогынты ясый. Татар халык биюен профессиональләштерүдә аерым роль уйный. Аның исеме беренче милли балет спектакле – Ф. Яруллинның «Шүрәле»се чыгу белән бәйле. Куелыштан тыш, ул оештыру мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә. Декадага әзерлек эшендә актив катнаша (1941).

1940 елда Мәскәүдә «Татар сәнгате декадасын үткәрү турында» карар чыкканнан соң, балет труппасының статусы үзгәртелә. Анда түбәндәге юлларны укыйбыз: «В связи с организацией при Татарском государственном оперном театре балетного коллектива с самостоятельными идейно-творческими задачами, призванного решать вопросы хореографического искусства в ТАССР, переименовать Татарский государственный оперный театр в Татарский государственный театр оперы и балета» (1941 елның 10 февраль карары) [11: 278]. Опера труппасыннан соң, балет труппасы да милли репертуар булдыру эшенә керешә. Декада уңаеннан, Мәскәүдә күрсәтелергә тиешле беренче татар балетын әзерли башлыйлар. Сюжет җентекләп сайлана. Әдәби чыганакка аерым таләпләр куела, алар турында без иҗат комиссиясенең «Таһир һәм Зөһрә» балеты турында фикер алышуга багышланган утырышы стенограммасыннан беләбез (1940 ел, 11 декабрь). Анда балетмейстерлар – декаданың баш балетмейстеры П. Гусев, В. Варковицкий, Г. Таһиров) дирижёрлар, композиторлар, педагоглар – С. Бергольц, Г. Литинский, Н. Җиһанов, А. Ключарев, Д. Садриҗиһанов, язучылар – Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, театрның сәнгать җитәкчелеге – С. Ходес, ТАССР ХКС[1] каршындагы сәнгать эшләре идарәсе җитәкчесе урынбасары Р. Ишморатов катнаша. Экспертлар сыйфатында Татар тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты вәкилләре – В. Хаҗиев, Б. Яфаров, Л. Җәләлетдинов чакырыла [10: 1].

Милли музыкаль спектакль өчен либреттоның нигезенә яткан чыганакка төп таләп – халыкның мәдәниятен, дөньяга карашын иң югары дәрәҗәдә чагылдыру. П. Гусевның татар сәнгате вәкилләреннән әлеге сюжетның татар фольклорына хасмы-түгелме икәнлеге турында ишетәсе килә [10: 1]. Чыганак «сәхнә өчен яраклы булырга», сәхнә кануннарына буйсынып үзгәртелергә тиеш була, әмма төп таләп күпләр авызыннан яңгырый: С. Ходес, мәсәлән, сюжетның хореографиягә киң мөмкинлекләр бирүе турындагы фикерне кабатлый, ләкин аны татар фольклорына якынлык мәсьәләсе борчый [10: 1].

Театр бердәнбер «Таһир һәм Зөһрә» варианты белән генә эшләми. 1939 елда Г. Литинский, Ф. Яруллин һәм Ә. Фәйзи беренче милли «Шүрәле» балетын иҗат итүгә алыналар. Либреттосы татар шагыйре

[1] ХКС – Халык комиссарлары советы.

Г. Тукай әсәрләренә таянып языла [10: 33]. «Шүрәле»нең куелышы расланганнан соң, эш активлаша. 1941 елның августында спектакльне Мәскәүдә декада кысаларында күрсәтергә ниятлиләр. Казан балет труппасы 24 биючедән генә торганлыктан, аны тулыландырырга кирәк була. Татар балетын тулы канлы итеп күрсәтү өчен 80 кешедән торган балет төркеме булдыру сорала: «Необходимо организовать группу миманса в составе 50 человек, которая в настоящий момент в театре совершенно отсутствует» [12: 14]. Н. Балтачеева һәм Г. Кумысниковтан тыш, Казанга Мәскәүдән А. Шатин җитәкчелегендәге «Остров танца» хореография коллективы килә. Иң яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен, Казанда белгечләрнең зур төркеме җыела. Декаданы нәтиҗәле әзерләү һәм уздыру өчен театрда югары квалификацияле осталар, баш режиссёрлар, опера режиссёрлары, югары квалификацияле балетмейстерлар җитешми [12: 13].

Эшләр гөрләп бара: репетицияләр, иҗади утырышлар, эш процесслары турында фикер алышулар, премьералар, иҗади конференцияләр үткәрелә, әмма декада булмый, Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, масштаблы планнар җимерелә. Шуңа да карамастан, октябрь ахырына кадәр, өзеклекләр белән булса да, декадага әзерлек эше тукталмый [2: 25]. 1941 елның 19 июлендә Татар дәүләт академия театры белән берлектә куелган «Хуҗа Насретдин» спектакленең премьерасы була. Н. Исәнбәтнең музыкаль комедиясендә (Җ. Фәйзи) хореографик күренешләрне балетмейстерлар П. Гусев, Л. Якобсон һәм Г. Таһиров куя. С. Сәйдәшевнең «Наемщик» музыкаль драмасы тамашачыга 12 ноябрьдә тәкъдим ителә. 1941 ел ахырына театр үзенең күп кенә хезмәткәрләрен фронтка озата. Штатны кыскарту барлык структураларга (цех, оркестр, опера һәм балет труппалары һ. б.) да кагыла, ләкин 1942 елда эш процессы активлаша. Ресурслары чикләнгән булса да, театр берничә ел эчендә Җ. Фәйзинең «Башмагым», «Акчарлаклар», Н. Римский-Корсаковның «Царская невеста», Ж. Бизеның «Кармен», Н. Җиһановның «Илдар», А. Даргомыжскийның «Русалка», Р. Леонкаваллоның «Паяцы», М. Юдинның «Фәридә» спектакльләрен, Ш. Гуноның бер актлы «Вальпургиева ночь» балетын һ. б. куя.

Сугыш елларында һәр премьера зур бер җиңүгә әверелә, театр авырлыклар һәм сынаулар тулы чорда аякка баса. Татар операсы камилләшә. Әлеге чорның иң мөһим казанышлары – милли балет хореография спектакльләре куелу: 1944 елда А. Ключаревның «Молодежь на отдыхе» бию сюитасының (Г. Таһиров куелышы), 1945 елның мартында Ф. Яруллинның беренче милли күп актлы «Шүрәле» балеты (Л. Жуков һәм Г. Таһиров куелышы) премьералары була. Либретто авторы – Ә. Фәйзи, спектакльнең бизәлеше П. Сперанскийныкы. Әйдәп баручы партияләрне беренче башкаручылар – Б. Әхтәмов, А. Виннерт, А. Гацулина, М. Карамышева.

Татар сәнгатенең яңа казанышы булган татар балетын булдыруда күптән көтелгән премьераның әһәмияте зур була. Спектакльне

әзерләү процессында әледән-әле иҗат комиссиясе утырышлары уздырыла. Чираттагы утырыш 6 мартта була [10: 9]. Катнашучылар арасында – спектакльнең балетмейстерлары Г. Таһиров һәм Л. Жуков, рәссам П. Сперанский, төп партияне башкаручы А. Гацулина, шулай ук композитор Н. Җиһанов, театр җитәкчелеге һ. б. Утырышның стенограммасы белән танышып, коллективның нинди кыенлыклар белән очрашуын белергә мөмкин. Ю. Виноградов болай ди: «Спектакль “Шурале” мы ждали очень давно, он готовился еще в 1941 г., но из-за войны постановка не состоялась. В период ожидания постановки этого спектакля балетная труппа перестала существовать» [10: 9]. 1945 елда хореография студиясе укучылары труппага ярдәмгә килә, бу спектакльнең сыйфатына йогынты ясамый калмый. Л. Жуков бу спектакльне яшь, тәҗрибәсез коллектив белән куярга батырчылык итүләрен белдерә [4: 16]. Хореографлар үз эшләренең йомшак якларын аңлыйлар һәм спектакльне камилләштерергә тырышалар. Г. Таһиров түбәндәгеләрне ассызыклый: «мне лично как постановщику танцев оперы “Алтын-Чеч” (“Алтынчәч”. – *Л.П.*) и балета “Шурале” хотелось бы услышать и детали, чтобы постепенно улучшать постановку <…> мне хотелось бы слышать подробную критику» [4: 20].

Сугыш елларындагы кысынкылыкларга карамастан, мондый иҗади утырышлар бик күп үткәрелә, эш кайнап тора. Комиссияләрдә сәнгать һәм фән эшлеклеләре катнаша. Фикер алышуларда төрле мәсьәләләр һәм темалар күтәрелә. Куелган спектакльләр тагын да камилләштерелә, премьералар һәм куючыларның репетицияләр этабындагы эше турында фикер алышулар үткәрелә. 1944 елның 11 апрелендә Җ. Фәйзинең «Акчарлаклар» музыкаль комедиясенә багышланган комиссия утырышы була [5: 3]. Анда язучылар, тикшеренүчеләр, театр вәкилләре һ. б. катнаша. Я. Агишев (Татар тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты) «Акчарлаклар»ны якты, бәйрәмчә, яшь әсәр дип бәяли. Л. Җәләлетдинов (Татар тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты) совет яшьләренең хис һәм кичерешләренең матур музыкаль тел аша сурәтләнүен билгели [5: 1]. Т. Гыйззәт сюжетка мәхәббәт проблемасы алыну һәм аның автор тарафыннан уңышлы хәл ителүе турында сөйли. Кимчелеге дип персонажларда комизм элементы аз булуны күрсәтә, аны көчәйтергә кирәклеген әйтә. Һәм әсәрнең һичшиксез кызыклы һәм кыйммәтле булуын искәртә.

Комиссиядә катнашучылар төрле аспектларга игътибар итәләр, детальләрне җентекләп карыйлар, нечкәлекләр һәм үзенчәлекләр турында фикер алышалар, анализлыйлар, тәнкыйтьлиләр. «“Акчарлаклар” спектаклен кабул итү турында»гы утырышта (1944 ел, 24 август) М. Юдин, Ю. Виноградов, Г. Таһиров, Җ. Фәйзи һ. б. катнаша. Профессор М. Юдин үзенең чыгышында спектакльне карарга җиңел булуын, күп кенә инструментларның җитенкерәмәвен искәртә. Ю. Виноградов сүзләреннән: «у композитора есть рост в смысле оркестровки, добился хорошей звучности <...> получилось смесь оперы,

оперетты и музыкальной комедии. Трудно понять смысл балета, иногда мешает ходу спектакля. Матросский танец – грубая буффонада <...> В работе художника условно выполнены задники, не верится что это река Волга с ее берегами».

Татар опера һәм балет театрының сәнгать җитәкчесе В. Бебутовның «ТДОБТның[1] милли театрлар смотрында катнашучы спектакльләре турында фикер алышу»га багышланган утырышта әйткән сүзләре (1945 ел, 14 апрель): «Мы слышали здесь выступление представителей Москвы с оценкой нашей работы. Прежде всего относительно жанра оперы. Начальник управления по делам искусств предложил мне высказаться о возможности существования оперетты в нашем оперном театре. Вся деятельность Немировича-Данченко и в частности моя доказывает, что ничего страшного здесь нет». Виноградов ахыр чиктә нәрсә закончалыклы – җыр башлангычымы яки мелодик речитативмы? дигән сорау бирә. Аңа икесенең дә закончалыклы булуын җиткерәләр [4: 21].

Милли музыкаль спектакль барлыкка килүнең бу чорында либретто мәсьәләсендә сораулар аеруча күп була. Кемдер беренче тапкыр либретто язарга алына. К. Нәҗми: «Мин – беллетрист язучы һәм миңа “Фәридә” операсын эшләү бик авыр булды <...> Либретто авторы буларак, бу әсәрнең зур кимчелекләрен үз өстемә алам, ләкин бу – иҗатымның беренче адымы булды» [4: 20], – дип белдерә.

Ә. Фәйзинең «Зөлхәбирә» операсы либреттосын тикшерүгә багышланган утырышта (1943 ел, 23 декабрь) М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, А. Ключарев, С. Сәйдәшев, И. Әүхәдиев, Ш. Сарымсаков, М. Юдин, Н. Җиһанов, М. Рахманкулова һ. б. – барысы 27 кеше катнаша [6: 1]. Татар язучылары кат-кат мөрәҗәгать иткән сюжетны сайлау тәнкыйтькә дучар ителә: «Либретто нужно было обсуждать до написания музыки. Автор Э. Файзи использовал фольклорный материал о девушке Зульхабире проигранной в карты, татарский народ много читал <...> В 1912 году на эту тему писал Р. Амирхан, в 1915 г. о Зульхабире писал Рашиди» [6: 1].

1941–1945 елларда Казанда узган утырышлардагы фикер алышулар һәм дискуссияләр милли опера һәм милли балетны камилләштерүгә хезмәт итә. Казанда күп гасырлык мирасны профессиональ сәхнәгә чыгару, аны саклап калу һәм тамашачыга җиткерә алырлык форма табу идеясе белән мавыккан композиторлар, рәссамнар, балетмейстерлар, режиссёрлар, галимнәр эшли. 1945 елда узган «Алтынчәч», «Фәридә» опералары һәм «Шүрәле» балеты турында фикер алышканда, И.А. Крути болай дип билгеләп үтә: «Мне кажется, что в трех спектаклях, которые мы просмотрели в самом содержании, как в музыкальных произведениях кроются такие элементы, которые придают им глубокую национальность и выводят их за пределы национальности. Эти произведения имеют достаточно оснований, что

[1] ТДОБТ – Татар дәүләт опера һәм балет театры.

бы сойти со сцены только национальных театров и приобрести всесоюзное значение... для всех этих произведений характерна глубочайшая лиричность <…> которая в минуту большого духовного напряжения переходит в героическую» [4: 8]. Спектакльләр кыска вакыт аралыгында әзерләнү сәбәпле, милли музыкаль спектакльнең иҗат принциплары да тизрәк формалаша.

Театр репертуары спектакльләрдән генә тормый, концертлар да әзерләнә, алар бай программа – дөньякүләм репертуардагы опера һәм балет спектакльләреннән күренешләр, яңа татар операларыннан өзекләр, хореографик номерлар белән аерылып тора. 1944 елда Татар дәүләт опера һәм балет театрының бишьеллыгына багышланган спектакль-концерт күрсәтелә. «Оборона фондына» концертлар уза. Башкаручылар – театрның әйдәп баручы артистлары: А. Измайлова, М. Рахманкулова, С. Садыйкова, А. Гацулина, У. Әлмиев, дирижёрлар – Д. Садриҗиһанов, И. Әухәдиев.

Казанга предприятиеләр эвакуацияләнә, госпитальләр җәелдерелә, заводлар эшли, ә кичләрен театр заллары тамашачылар белән тула. Ә. Айдарская истәлекләреннән: «Спустя год я вновь, совсем как в сказке, оказалась на сцене театра оперы и балета. Он гостеприимно распахнул свои двери – в затемненном, переполненном эвакуированными организациями, жителями и военными госпиталями, настороженном городе» [1].

Татар дәүләт опера һәм балет театры көненә берничә спектакль куярга планлаштыра, әмма аларның кайберләре булмыйча да кала, артистлар ачлыктан һәм эш шартларының авырлыгыннан хәлсезләнә. Театр ачылганчы ук берничә проблема белән очрашырга туры килә, иң мөһиме – бина мәсьәләсе: театр махсус театр бинасы, шулай ук ярдәмче остаханәләр өчен бүлмәләр җитәрлек булмаган шартларда оештырыла, аларның юклыгы үзен нык сиздерә. Артистлар шәһәрнең төрле мәйданчыкларында, күбесенчә Татар дәүләт академия театры һәм рус драма театры сәхнәләрендә чыгыш ясыйлар, репетицияләр начар җылытылган, уңайлыклары булмаган биналарда уза. Ә. Айдарская әлеге шартларны тәфсилләп тасвирлый: «Наш балетный коллектив, не имея своего помещения для занятий, мытарствовал по клубам. Иногда занимались, держась за горячие трубы, стулья, барьеры <...>Танцевать приходилось на каменном полу и лестничных площадках, в палатах раненых и кузовах грузовиков, иногда прямо под открытым небом» [1]. Г. Таһиров та артистлар белән бергә Казаннан читтә, соңрак шәһәрнең үзендә урман кисә, ныгытмалар төзүдә катнаша, госпитальләрдә, эвакуация пунктларында концертлар бирә [2: 25]. Опера труппасы солисты Ф. Насретдинов һәм Татар дәүләт опера һәм балет театрының башка бик күп артистлары госпитальләрдә, яралы солдатлар алдында чыгыш ясый.

Бөек Ватан сугышы башлану белән илдәге артистларның тормышы тамырдан үзгәрә. Театрларда эшләүдән, госпитальләрдә чыгыш ясаудан тыш, алар концерт бригадаларына берләшәләр, фронтка

бик якын урыннарда да булалар. Казанда 1942 елга 3 концерт бригадасы оештырыла, алар «фронт яны зоналарына» чыгалар. Әлеге бригадаларга ТАССРның халык артисткасы Измайлова, ТАССРның атказанган артисты Шәмсетдинов, опера солистлары: Маев, Пустоветов, Артёмов, Герасимов һәм шәһәрнең иҗат коллективлары артистлары керә [15].

Иҗат коллективлары шулай ук актив концерт эшчәнлеге белән дә шөгыльләнәләр, госпитальләрдә, частьларда чыгыш ясыйлар. ТАССР ХКС каршындагы Сәнгать эшләре идарәсе һәм Сәнгать әһелләре (РАБИС) берлеге Татарстан өлкә комитетының бер ел өчен хисабы, 22.06.1941–1.05.1942: «Эшче-крестьян Кызыл армиясе (ЭККА) һәм эвакогоспиталь частьларына сәнгать әһелләренең мәдәни шефлыгы рәвешендә түбәндәге чараларны үткәрделәр: концертлар – 2586» [15]. Шулардан госпитальләр өчен – 1866, ЭККА частьлары өчен – 324.

Сугыштагы солдатларның рухын күтәрүдә артистлар чыгышларының әһәмияте зур була. Сержант А. Сәйфуллинның Г. Динмөхәммәтовка язган хатыннан: «үземнең кечкенә генә хатымда сез җибәргән Татарстан дәүләт филармониясе артистларының делегация рәисе җитәкчелегендә <...> безнең частьта булулары һәм аның дүртьеллыгы уңаеннан концерт күрсәтүләре турында хәбәр итәргә телим. Шуның белән бергә татар сугышчылары, сержантлары, офицерлары һәм гомумән сезнең артистларыгызның концертын караган частебызның бөтен шәхси составы исеменнән тирән рәхмәтемне белдерергә рөхсәт итегез <...> безгә туган телебездә музыка тыңлау бик кадерле <...> Без фронтовиклар, үзебезнең милли гимннарыбызны тыңлап, алдагы сугышлар өчен көч туплыйбыз» [13: 2].

Бөек Ватан сугышы чорында, шартлар авыр булуга карамастан, Татар дәүләт опера һәм балет театры актив иҗат итә, концерт эшчәнлеге алып бара (госпитальләрдә биргән концертларны да кертеп). 1941 елның августында Мәскәүдә үткәрелергә тиешле татар сәнгате һәм әдәбияты декадасына әзерлек эшләре дә сугыш елларында республиканың балет һәм опера сәнгатен үстерү өчен шартлар тудыра. Театр милли репертуар, опера һәм балет спектакльләре кую юнәлешендә нәтиҗәле эшли, һәм бу аның алга таба үсешен тәэмин итә. Иҗади утырышлар булып тора, аларда милли музыкаль спектакльнең принциплары һәм алымнары турында фикер алышалар; премьералар тикшерелә; сәхнәгә куелган спектакльләр камилләштерелә.

### Әдәбият

1. *Айдарская А.Г.* Балет – любовь моя: записки балерины. Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. 95 с.

2. *Горшков В.Н.* Балетмейстер Гай Тагиров. Казань: Научно-методический центр народного творчества МК РТ, 1997. 47 с.

3. *Горшков В.Н.* Из истории татарского балета // Татарский академический театр оперы и балета имени Мусы Джалиля / под общ. ред. Г.М. Кантора; Казань: Казан. гос. консерватория, 1994. С.89–106.

4. Дом актера им. М. Салимжанова. СТД РТ: Ф. 10. П. 13.

5. Дом актера им. М. Салимжанова. СТД РТ: Ф. 10. П. 10.

6. Дом актера им. М. Салимжанова. СТД РТ: Ф. 10. П. 9.

7. Дом актера им. М. Салимжанова. СТД РТ: Ф. 10. П. 42.

8. *Маклыгин А.Л.* Невзятые вершины «национального музыкального строительства» // Вестник Санкт-Петербургского университета. Искусствоведение. Т. 10, № 4. 2020. С. 539–559.

9. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 6663. Оп. 1 Д. 9.

10. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 6663. Оп. 1 Д. 29.

11. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 6663. Оп. 1. Д. 34.

12. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 6663. Оп. 1. Д. 16.

13. Музейный комплекс города Казани. Письмо сержанта А.Х. Сайфуллина. 1943. Номер в Госкаталоге РФ – 500/359.

14. Музейный комплекс города Казани. Программа «Спектакль-концерт». 1944. Номер в Госкаталоге РФ – 500/340.

15. Музейный комплекс города Казани. Отчет Управления по делам искусств (копия). 1942. Номер в Госкаталоге РФ – 500/3491.

16. Эвакуация в ТАССР в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. URL: https://ga.tatarstan.ru/internet-vistavki.htm?pub_id=3783928 (дата обращения: 27.04.2026).

***Петрова Луиза Раниф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

***Петрова Луиза Ранифовна,***
*научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*luizapetro8a@mail.ru*